**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, нос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУШЩИИАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Бнектау т/ю сганциясе носелогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**04.04.2022 ел** **№ 391**

**«2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары (2021 елның 24 декабренә үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү концепциясен раслау турында» 2006 елның 30 мартындагы 136 номерлы карары, Биектау муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүдә муниципаль ярдәм итү максатларында, КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып игълан итәргә,
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының 2022 елның
«04» 04 391 нче номерлы
карары белән расланды

# «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасы

Биектау т.юл стан. пос., 2022 ел

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасы (алга таба - Программа) |
| **Программаны эшләү өчен нигез** | Халыкның ШЯХ ларын хокукый җайга салу түбәндәге норматив актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>-Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе;<br>- Россия Федерациясе Гражданнар кодексы;<br>-«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-1 номерлы Федераль закон;<br>- «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» 1995 елның 8 декабрендәге 193-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына ярдәм чаралары турында» 2015 елның 26 февралендәге 120 номерлы карары. |
| **Программаның заказчысы** | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Төп эшләүчеләр** | Биектау муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе катнашында Биектау муниципаль районы башкарма комитеты; |
| **Программаның максаты** | шәхси ярдәмче хуҗалыкларның (ШЯХ) тотрыклы эшләвен тәэмин итү һәм мөгезле эре терлекнең баш санын арттыру исәбенә аларның табышлылыгын күтәрү, базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, шәхси ярдәмче хуҗалык ияләренең (физик затларның) икътисади мәнфәгатьләрен яклау. |
| **Программаның бурычлары:** | Савым көтүенең продуктивлылыгын күтәрү һәм баш санын арттыру нигезендә терлекчелек продукциясе күләмен арттыру; |

<table>
<tr><td></td><td>авыл халкы тормышының матди дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт шартларын һәм мәшгульлеген яхшырту.</td></tr>
<tr><td>Программа чараларын төп башкаручылар</td><td>Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>Биектау районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе;<br>Авыл җирлекләренең башкарма комитетлар</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары</td><td>2022-2024 еллар</td></tr>
<tr><td>Финанслау чыганаклары</td><td>Программаны финанслау күләме Биектау муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәре исәбеннән 3 000,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
<table>
<tr><td>2022 ел</td><td>1 000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td>2023 ел</td><td>1 000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td>2024 ел</td><td>1 000,0 мең сум</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Биектау муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре</td><td>Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисади нәтиҗәлелек түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүдән;<br>- район авылларында яшәүчеләрнең нормаль көн күрүе өчен шартлар булдырудан;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыкларның (ШЯХ) тотрыклы эшләвен тәэмин итүдән;<br>- 2021 ел дәрәҗәсенә мөгезле эре терлекләрнең баш санын ел саен кимендә 10 %ка арттыру исәбенә керемнәрне арттырудан;<br>- базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрүдән;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләренең (физик затларның) икътисади мәнфәгатьләрен яклаудан.</td></tr>
<tr><td>Программа чараларына контроль системасы</td><td>Биектау районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе;<br>Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
</table>

## 1. Проблемага характеристика һәм аны программа ысуллары белән хәл итүнең зарурлыгын нигезләү

Авыл хуҗалыгының тотрыклы үсеше төрле милек формаларындагы хуҗалыкларның гармонияле эшләвен күз алдында тота. Агросәнәгать комплексында җитештерүне оештыруның иң уңайлы һәм динамикалы формаларының берсе булып шәхси ярдәмче хуҗалыклар (алга таба - ШЯХ) тора, аларның төп бурычы - гаилә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү. Халыкның ШЯХ лары авылда яшәүчеләр өчен туклану продуктлары керүнең төп чыганакларының берсе һәм Россиянең, шул исәптән Татарстан Республикасының да азык-төлек базарының актив субъекты була бара. Авыл хуҗалыгы милли икътисадның иң мөһим өлкәсе булып тора, ул агросәнәгать комплексында үзәк буынны төзи.

Республиканың аграр сәясәте кысаларында федераль һәм республика максатчан программалары гамәлгә ашырыла.

Бюджет ярдәме ысуллары тагы да максатчанрак кулланыла башлады, бюджет чаралары хисабына процент ставкалары өлешен субсидияләү нигезендә кредит бирү ысуллары камилләштерелде, авыл хуҗалыгы җитештерүен һәм азык-төлек базарын дәүләт көйләве ысулларын файдалану киңәя төште.

Әмма күрелә торган чараларга карамастан, районның шәхси хуҗалыкларында мөгезле эре терлекнең баш саны кимү тенденциясе бара, продуктивлыкның аерым күрсәткечләренең ирешелгән дәрәҗәсе җитәрлек түгел.

Чаралар комплексын тормышка ашыру нигезендә әлеге мәсьәләне хәл итү хуҗалык итүнең кече формаларын тотрыклы үстерү өчен шартлар булдыруны, терлекчелек продукциясе җитештерүне һәм малларның баш санын тизләтелгән рәвештә арттыруны тәэмин итәчәк.

Үзләренең төп функциясен – авыл хуҗалыгы продукциясе белән үз-үзен тәэмин итүне башкарып, халыкның ШЯХ лары районның азык-төлек базарын сизелерлек тулыландыралар. Халыкның ШЯХ лары торак пункттагы социаль мәсьәләләрне хәл итүгә шактый зур ярдәм итә һәм, барыннан да бигрәк, авыл кешесенең мәшгульлеген тәэмин итүгә, үзеннән арткан авыл хуҗалыгы продукциясен сатып, өстәмә керем алуга булышлык итә. Шулай итеп, халыкның ШЯХ лары, икътисадый институт буларак, авыл берләшмәсенең социаль тотрыклылыгының фундаменталь нигезен тәшкил итәргә тиешләр.

Халык ШЯХ ларының күпчелеге, йорт яны кишәрлекләреннән алынган азыкны файдаланып, шулай ук арендага бирелгән җир пайлары (өлешләре) өчен түләү сыйфатында алынган авыл хуҗалыгы продукциясен файдаланып, терлекчелек продукциясе җитештерүне алып баручы гаилә хуҗалыклары булып тора.

2022 елның 1 гыйнварына Биектау районында халык шәхси ярдәмче хуҗалыкларында авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү белән авыл җирлекләре буенча 20202 йорт хуҗалыгы шөгыльләнә. Район халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында 5023 баш мөгезле эре терлек бар, шуларның 1799 башы сыерлар.

**2022 елның 1 гыйнварына ШЯХ ларда авыл җирлекләре киселешендә йорт хуҗалыклары саны һәм терлекләрнең булуы турында мәгълүмат**

| Авыл җирлеге исеме | йортлар саны | МЭТ баш саны | шул ис. сыерларның |
|---|---|---|---|
| Айбаш АҖ | 400 | 312 | 132 |
| Алан-Бәксәр АҖ | 263 | 94 | 40 |
| Әлдермеш АҖ | 335 | 562 | 250 |
| Каенлык АҖ | 663 | 558 | 187 |
| Бөреле АҖ | 440 | 216 | 29 |
| Олы Битаман АҖ | 372 | 681 | 165 |
| Олы Кавал АҖ | 213 | 419 | 172 |
| Биектау АҖ | 6743 | 63 | 9 |
| Дачный АҖ | 240 | 1 | 1 |
| Дөбъяз АҖ | 751 | 112 | 43 |
| Иске Казан АҖ | 491 | 235 | 85 |
| Казаклар АҖ | 238 | 41 | 22 |
| Красносельский АҖ | 2899 | 4 | 3 |
| Коркачык АҖ | 610 | 30 | 9 |
| Мәмдәл АҖ | 344 | 345 | 96 |
| Мүлмә АҖ | 343 | 212 | 82 |
| Алат АҖ | 459 | 90 | 28 |
| Семиозерка АҖ | 1213 | 37 | 17 |
| Суыксу АҖ | 241 | 312 | 174 |
| Ташлы Кавал АҖ | 186 | 167 | 87 |
| Усад АҖ | 680 | 95 | 50 |
| Чыпчык АҖ | 749 | 55 | 12 |
| Чернышевка АҖ | 527 | 54 | 36 |
| Шәпше АҖ | 439 | 45 | 11 |
| Ямаширмә АҖ | 363 | 283 | 59 |
| **Район буенча БАРЛЫГЫ** | **20202** | **5023** | **1799** |

## 2. Муниципаль программаның максаты һәм бурычлары

Халык ШЯХ ларын тотрыклы үстерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген күтәрүгә дәүләт ярдәмен исәпкә алып тәэмин итү;

Икътисадның әлеге секторына икътисадый һәм социаль ярдәм.

Куелган максатларга түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән ирешергә мөмкин:

халык ШЯХ ларының нәтиҗәле эшчәнлегенә ярдәм итүче хокукый база һәм икътисадый уңай шартлар булдыру;

халык ШЯХ ларын җир кишәрлекләре белән тәэмин итү;

азык базасын киңәйтү;

халык ШЯХ ларын финанс белән тәэмин итү механизмнарын булдыру;
авыл халкының социаль шартларын яхшырту һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрү;
авылдагы икътисадый актив халыкның мәшгульлеген арттыру;
халык ШЯХ ларының хезмәттәшлегенең һәм кооперацияләштерүнең нәтиҗәле механизмын булдыру;

Әлеге Концепция кысаларында үткәрелә торган төп чаралар түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

халык ШЯХ ларын үстерүне законнар һәм башка нормативлар белән тәэмин итүне камилләштерүгә;

халык ШЯХ ларының авыл хуҗалыгы оешмалары, крестьян (фермерлык) хуҗалыклары, эшкәртү һәм сәүдә предприятиеләре белән хезмәттәшлеген камилләштерүгә һәм базар интеграциясенең бүтән формаларын оештыруда булышлык күрсәтүгә;

халык ШЯХ ларына финанс-кредит ярдәме күрсәтүгә;

халык ШЯХ ларына мәгълүмати-консультация хезмәте күрсәтүне оештыруга;

халык ШЯХ ларына ярдәм итүдә җирле үзидарәнең ролен күтәрүгә.

Хуҗалык итүнең кече формаларының авыл хуҗалыгы җитештерүенең динамикалы икътисадый үсешен, авыл халкының мәшгульлеген тәэмин итүдә һәм аның тормыш дәрәҗәсен яхшыртудагы ролен күтәрү өчен алга таба авыл хуҗалыгында, шул исәптән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне һәм эшкәртүне оештыру өлкәсендә эшкуарлыкның кече формаларын үстерү күздә тотыла.

### 3. ШЯХ оештыруның һәм эшләвенең хокукый нигезләре

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» Федераль закон, бүтән федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук алар нигезендә кабул ителгән Биектау муниципаль районы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шәхси ярдәмче хуҗалык, санап үтелгән хокукый актлар нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яки) сатып алынган җир кишәрлегендә шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм эшкәртү буенча граждан һәм аның гаилә әгъзаларының эшкуарлыкка карамаган эшчәнлек формасы булып тор.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри пенсия иминияте буенча хокук мөнәсәбәтләренә керергә хокуклы.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару бердәнбер табыш чыганагы булып торган хезмәткә яраклы яшьтәге гражданнар, шәхси ярдәмче хуҗалыкта җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан килгән керемне дә кертеп, гаиләнең җан башына туры килүче кереме Татарстан Республикасы буенча билгеләнгән яшәү минимумыннан артык булмаган шартта эшсез дип танылалар.

Гражданнар шәхси ярдәмче хуҗалыкларында җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукцияләрен ирекле рәвештә, үзләре теләгәнчә муниципаль һәм башка базарларда, җитештерү һәм кулланучы авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм башка

юридик затлар аркылы эшкәртү һәм хәзерләү предприятиеләренә, оешмаларына сата алалар.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның мөлкәте әлеге максатларда бирелгән, алынган яисә сатып алынганган җир кишәрлегеннән, терлек, кош-кортлар, бал кортларыннан, күпьеллык утыртмалардан (куаклыклар, агачлар), торак биналардан, хуҗалык һәм башка корылма һәм каралты-кураларыннан, авыл хуҗалыгы техникасыннан, җиһазлардан, инвентарьдан, транспорт чараларыннан һәм бүтән матди чыганаклардан, җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясеннән һәм аның эшкәртелгән продуктларыннан торырга мөмкин.

Халык шәхси ярдәмче хуҗалыгы мөлкәтенең барлыкка килү (оешу) чыганаклары булып торырга мөмкин:

-шәхси ярдәмче хуҗалык иясе һәм аның гаилә әгъзаларының акча һәм матди чаралары;

- җитештергән продукциясен сатканнан килгән керемнәр;

-шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм авыл хуҗалыгы җитештерү һәм куллану кооперативларында, бүтән оешмаларда эшләүче гражданнар эшчәнлегеннән керемнәр;

-кыйммәтле кәгазьләрдән керемнәр;

-бюджеттан дотацияләр һәм дәүләт ярдәменең башка төрләре;

-банклар һәм бүтән финанс учреждениеләре кредитлары;

-гражданнар һәм юридик затларның хәйриячелек һәм кире кайтарылмый торган взнослары, иганәләре, шул исәптән мирас тәртибендә, бүләк ителү яисә башка законлы нигездә алынган мөлкәт;

-натуралата түләү яки арендага алу тәртибендә авыл хуҗалыгы оешмаларыннан һәм шәхси эшмәкәрләрдән алынган терлек һәм бүтән матди чаралар;

-Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар.

## 4. Җир мөнәсәбәтләре, җир биләү һәм җирдән файдалану механизмын камилләштерү

Җир мөнәсәбәтләрен камилләштерү гражданнарның җиргә конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруга, җирнең базар әйләнешен формалаштыру механизмын булдыруга юнәлдереләчәк.

Шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләре өчен, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен муниципаль милектәге җирләрдән милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән билгеләнәчәк.

Җирләрне рациональ оештыруны, инженерлык төзелешен һәм алардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә торган җир төзелеше эшләре комплексын гамәлгә ашыру һәм аларның максатчан билгеләнеше буенча җирләрдән файдалануны контрольдә тотуны көчәйтү планлаштырыла.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру механизмы һәм тәртибе

Программаны реализацияләү механизмы булып Программа чараларын башкаручыларның азык-төлек куркынычсызлыгы торышын яхшырту, район авыл халкының тормыш сыйфатын яхшырту, терлекнең баш санын һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру өчен нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле авыл хуҗалыгы җитештерүе булдыруга юнәлтелгән яраштырылган гамәлләре тора.

Шуңа бәйле рәвештә, Программаны гамәлгә ашыру кысаларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга түбәндәге муниципаль ярдәм чараларын алга таба үстерү күздә тотыла:

- терлекчелек продукциясен (сөт) җитештерүне субсидияләү;
- шәхси ярдәмче хуҗалыкларның товарлыгын арттыру.
- терлек азыгы базасын киңәйтү;
- шәхси ярдәмче хуҗалыклардан терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясен сатып алулар,
- ШЯХ алып бару өчен җир кишәрлекләре бирү,
- нәсел эшен оештыру;
- халык ШЯХ ларында терлекләрнең продуктивлыгын арттыру турында кайгырту;
- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда, дачаларда, бакчаларда, яшелчә бакчаларында үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен базарлар территориясендә бушлай сәүдә урыннары бирү;
- авыл хуҗалыгы ярминкәләрен оештыру.

### 5.1. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүгә гражданнарның чыгымнары өлешен каплау (субсидияләү)

Финанс ярдәме алу хокукына Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм гамәлдәге законнар нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы авыл хуҗалыгы продукциясе һәм чималы җитештерү, эшкәртү һәм реализацияләү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы һәм әгъзалары, индивидуаль эшкуарлар булып торучы гражданнардан башка гражданнар ия.

ШЯХ алып баручы гражданнарга финанс ярдәме алу өчен 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча гариза бирү зарур. Гариза авыл җирлеге башлыкларына ел саен **1 сентябрьгә кадәр** бирелә.

Авыл җирлеге - бюджеттан матди ярдәм алучыны сайлап алу ел саен уздырыла.

Савым сыерларының баш саны 2021 елга караганда кимендә 10%ка арткан авыл җирлекләре район бюджетыннан финанс ярдәме алуда катнаша ала.

Әлеге авыл җирлекләрендә финанс ярдәме алырга теләүче гражданнарга авыл җирлегенә гариза бирергә кирәк. Гариза нигезендә авыл җирлеге 2 нче кушымта нигезендә форма буенча финанс ярдәме белешмәсен - исәп-хисабын әзерли. Белешмә районның Финанс-бюджет палатасына тапшырыла.

Матди ярдәм күләме:

- савым сыерларын 1 башка арттырганда (хуҗалыкта 2 һәм аннан да күбрәк сыер булган шартта) - 20 000 (егерме мең) сум.

Сыерларның булуын раслаучы документ булып хуҗалык кенәгәсе тора.

Квартал саен финанс ярдәме алган шәхси ярдәмче хуҗалык гражданнары авыл җирлегенә сыерларның баш саны турында мәгълүмат бирергә тиеш.

Финанс ярдәмен алуның зарури шарты булып 3 ел дәвамында сыерларның баш санын саклап калуны тәэмин итү тора.

Финанс елы дәвамында файдаланылмаган ассигнованиеләр лимитлары киләсе финанс елында финансланырга тиеш түгел.

## 5.2. Программаны үтәү критерийлары

Программа чаралары шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүне тәэмин итәргә һәм район халкының нормаль тормышы өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программа үтәлеше критерие булып савым сыерларының баш саны 2021 ел дәрәҗәсенә карата ел саен кимендә 10 %ка артуы тора.

## 6. Контрольне оештыру

Башкарма комитет бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны контрольдә тота һәм Программаның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрә. Шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы, максатчан файдаланмау фактлары ачыкланганда, бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәләре район Башкарма комитетында авыл җирлекләре башлыклары катнашында тикшерелә.

Программаны гамәлгә ашыру турында квартал саен район Башлыгына хисап бирелә.

1 нче кушымта

Финанс ярдәмен алуга
гариза

Мин ________________________________________________________________
(шәхси ярдәмче хуҗалык иясенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________________________________________адресы буенча яшим
(яшәү урынының адресы)

Мине финанс ярдәме алуга программада катнашучылар составына кертүегезне сорыйм.

Катнашучы турында мәгълүматлар:

1. Паспорт мәгълүматлары:
сериясе_________№______________________________________________
Кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән:
_______________________________________________________________
ИНН _______________________________________________
СПС_______________________________________________
2021 елның 31 декабренә сыерлар_____________________________ баш иде
2022 елның 01 июленә сыерлар_____________________________ баш булды

2.Элемтә телефоны, E-mail _________________________

Гариза бирү датасы «___» _______, 202__ел.

Шәхси ярдәмче хуҗалык
иясенең имзасы
______________/__________________________________________/

2 нче кушымта

Финанс ярдәме белешмәсе-исәп-хисабы

| | |
|---|---|
| ШЯХ Ф.И.А. тулысынча | |
| 2021 елның 31 декабренә сыерлар саны | |
| 2022 елның 01 июленә сыерлар саны | |
| 31.12.2021 ел – 01.07.2022 ел чорында сырлар саны арту, баш | |
| Савым көтүе 1 башка артканда, материаль ярдәмнең күләме, сум. | 20 000 сум. |
| ШЯХ хуҗасына тиешле матди ярдәмнең гомуми күләме, сум. | |

Дата

Авыл җирлеге башлыгы (Ф.И.А., имза, мөһер)

Биектау районы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе вәкиле (Ф.И.А., имза, мөһер)

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесенең урынбасары (Ф.И.А., имза, мөһер)